**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» 04 2021 ел Яр Чаллы №1028

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 августындагы «Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 8 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 327 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 3208 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы район Башкарма комитеты карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 августындагы 3208 карары 1 кушымта) белән расланган Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты аша муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – әлеге органга мөрәҗәгать итүче тапшырырга бурычлы документларны тапшырганнан соң кырык биш көннән дә соңга калмыйча.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Гаризада күрсәтелгән адрес буенча, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны бирү яки җибәрү бинаны күчерү яки күчерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

2) 2.5 пунктында:

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) Күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләренең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә аларның ризалыгы турында карарны үз эченә алган гомуми җыелышының беркетмәсе;»;

түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктны өстәргә:

7) Күчерелә торган бинага янәшә булган барлык биналарның һәр милекчесенең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.»;

3) 2.8 пунктның дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлектәге сүзләрне өстәргә:

«Әгәр биналарны күчерүне башкаручы орган, күрсәтелгән җавапны алганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә мондый җавап алуы турында хәбәр иткән булса, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документны һәм (яки) мәгълүматны тапшырырга тәкъдим иткән һәм мөрәҗәгать итүчедән мондый документларны һәм (яки) мәгълүматны хәбәрнамә җибәргәннән соң унбиш эш көне эчендә алмаган очракта, бинаны әлеге нигез буенча күчерүдән баш тарту рөхсәт ителә.»;

4) 5.1 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлек Советы» сүзләрен «муниципаль берәмлек башлыгына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 августындагы 3208 номерлы карары белән расланган Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (1 кушымта), Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (2 кушымта) 3.3.1 пунктында «КФҮ, КФҮнең читтән торып эш урыны аша» сүзләрен төшереп калдырырга».

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 августындагы 3208 номерлы карары белән расланган Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 кушымта), Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2 кушымта), Муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яки өлешчә уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне

автомобиль белән ташу өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (3 кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.14 пунктка түбәндәге эчтәлектәге дүртенче-сигезенче абзацларны өстәргә:

«Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатында тәэмин ителә:

1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылулары булган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат туплагычларны, аларның тормыш эшчәнлегендәге чикләүләрне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-ноктаны шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче хезмәтенә рөхсәт;

6) махсус өйрәтелүен раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Йөртүче этне махсус өйрәтүне раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документы булганда, йөртүче этне бинага кертергә рөхсәт.

Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга инвалидларның керүен һәм әлеге пунктның 1-4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган средстволардан инвалидларның файдалануын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.»;

2) 5 бүлеккә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе»;

5.2 пунктта:

икенче абзацта «КФҮ аша» төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге өченче абзацны өстәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр югары органга (булганда) бирелә яисә ул булмаганда, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.»;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин